ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д. 3, с. Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк урамы, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

# КАРАР

« 14 » ноябрь 2022 ел № 22

**2023 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын раслау турында**

«Контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын раслау турында» РФ Хөкүмәтенең 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында 2023 елга закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл җирлеге
башкарма комитетның
14.11.2022 ел, № 22
карарына кушымта

2023 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасы

Әлеге 2023 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасы (алга таба – профилактик программа) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль өлкәсендәге зарарны (зыянны) профилактикалау программасын эшләү һәм раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы карары нигезендә нигезендә эшләнде һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне (алга таба-муниципаль контроль) гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау буенча чаралар комплексын күздә тота.

Программа түбәндәге бүлекләрдән тора:

1.Контроль төрен гамәлгә ашыруның агымдагы торышын анализлау, контроль (күзәтчелек) органы профилактик эшчәнлегенең агымдагы үсеше тасвирламасы, профилактик программа юнәлдерелгән проблемаларга характеристика;

2.Профилактик программаны гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары;

3.Профилактик чаралар исемлеге, аларны уздыру сроклары (вакыты);

4.Профилактик программаның нәтиҗәлелеге һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре.

**1 нче бүлек. Контроль төрен гамәлгә ашыруны анализлау һәм бәяләү, контроль (күзәтчелек) органы профилактик эшчәнлегенең агымдагы**

**үсешен тасвирлау, профилактик программа аларны хәл итүгә юнәлдерелгән проблемаларга характеристика**

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) .

Муниципаль контроль предметы түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- юридик затлар, шәхси эшкуарлар һәм гражданнар тарафыннан (алга таба - контрольдә тотылучы затлар) җирләрдән файдалану өлкәсендә Россия Федерациясе законнары белән бозган өчен административ җаваплылык каралган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү (алга таба-мәҗбүри таләпләр);

- контрольдә тотылучы затлар тарафыннан рөхсәт документларындагы таләпләрне үтәү;

- үтәлеше Россия Федерациясе законнары нигезендә кирәкле документлар таләпләрен үтәү;

- контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларны үтәү.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда түбәндәгеләр үткәрелергә мөмкин:

-профилактик чаралар;

-контроль чаралар.

Төзекләндерү өлкәсендә контроль предметы булып юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар тарафыннан җирлекне төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү тора.

2020-2021 елларда контрольдә тотылучы субъектларга карата планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрелмәде.

Контрольдә тотылучы затлар тарафыннан законнарның мәҗбүри таләпләрен үтәүгә, контрольдә тотылучы затларны яклауга юнәлдерелгән профилактик чаралар үткәрү тулаем ситуацияне яхшыртуга, контрольдә тотылучы затларның җаваплылыгын күтәрүгә, ачыкланган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозулар санын киметүгә ярдәм итәчәк.

## 2 нче бүлек. Профилактик программаны гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары.

2.1.Программаның төп максатлары түбәндәгеләр:

-барлык контрольдә тотылучы затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәүне стимуллаштыру;

- мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яисә) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүгә китерергә сәләтле шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;

- контрольдә тотылучы затларга мәҗбүри таләпләрне җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында мәгълүматлаштыруны арттыру.

2.2.Профилактик программа чараларын үтәү түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

-закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын бозуларны профилактикалау системасын ныгыту;

-дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең, юридик затларның, шәхси эшкуарларның һәм гражданнарның хокукый аңын һәм хокукый культурасын күтәрү;

-гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян килүне киметүгә ярдәм итә торган профилактик чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру мөмкинлеген бәяләү;

- гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерү куркынычы факторларын ачыклау, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау, куркынычларны бетерү яки киметү ысулларын билгеләү.

## 3 нче бүлек. Профилактик чаралар исемлеге, аларны уздыру сроклары (вакыты)

| № | Чаралар исеме | Аларны уздыру сроклары (чираты) | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | **Мәгълүмат бирү**<br>Башкарма комитет мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча контрольдә тотылучы затларга мәгълүмат бирә.<br>Мәгълүмат бирү тиешле мәгълүматны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла. | Даими | Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитет җитәкчесе |
| 2 | **Консультация бирү**<br>Телдән консультация бирү вазыйфаи затлар тарафыннан телефон аша, видеоконференцэлемтә аша, шәхси кабул иткәндә түбәндәге мәсьәләләр буенча контроль чара, профилактик чара үткәрү барышында уздырыла: | Ел агымында (кирәк булганда) | Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитет җитәкчесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | а) Арча муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты адресы, урнашкан урыны, контакт телефоннары һәм электрон почта адреслары;<br>б) инфраструктура үсеше бүлегенең эш графигы, килүчеләрне кабул итү вакыты;<br>в) муниципаль контрольне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча килүчеләрне кабул итү һәм аларга мәгълүмат бирү үткәрелә торган кабинетларның номерлары;<br>г) муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге;<br>д) мәҗбүри таләпләре булган актлар исемлеге.<br>Язма рәвештә консультация бирү контрольдә тотылучы затларның һәм аларның вәкилләренең түбәндәге мәсьәләләр буенча язма мөрәҗәгатенә җавап җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла:<br>а) контрольдә тотылучыны яисә файдаланыла торган объектны куркынычлылык категориясенә кертү өчен нигез;<br>б) контрольдә тотылучы яисә файдаланыла торган контроль объектларына карата планлаштырылган контроль чаралары булу.<br>Муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру турында язма җаваплар бирү, бер типтагы мәсьәләләр буенча консультацияләр бирү турында контрольдә тотылучы затлардан өчтән артык бер типтагы гариза кергән очракта, муниципаль контроль органының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган язма аңлатманы Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https:/ arsk.tatarstan.ru/ адресы буенча Арча муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла. | | |

## 4. Профилактик программаның нәтиҗәлелеге һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре

4.1.Программаның максатчан индикаторлары һәм сыйфат күрсәткечләре һәм нәтиҗәлелеге түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеге турында контрольдә тотылучы субъектларга мәгълүмат бирү;

мәҗбүри таләпләрнең билгеләнеше, аларны муниципаль контроль органының контроль субъектлары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан бертөрле аңлау;

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган мәҗбүри таләпләрнең кабул ителгән һәм әзерләнә торган үзгәрешләре турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән контрольдә тотылучы субъектларның канәгать булуы;

тикшерүләр уздырганда контрольдә тотылучы субъектларның хокуклары, аларны уздыру тәртибе турында контрольдә тотылучы субъектларга мәгълүмат бирү;

профилактик программа чараларын үтәү.

Программаны гамәлгә ашыруның төп күрсәткече булып профилактик чаралар үткәрү тора.

4.2.Календарь ел нәтиҗәләре буенча программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен, күрсәтелгән программада профилактик программа максатларына ирешүне исәпкә алып, түбәндәге сан күрсәткечләре билгеләнә:

| № | Индикатор | Күрсәткечләр |
|---|---|---|
| 1 | Җир законнарының мәҗбүри таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча контрольдә тотылучы затларга мәгълүмат бирү буенча сайтта урнаштырылган язмалар саны | 2 |
| 2 | Консультация бирү | 12 |